РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«18» июля 2022 ел г. Альметьевск № 1492

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль
районының Балалар һәм яшьләр эшләре
идарәсенә гамәлгә куючының аерым
функцияләрен һәм вәкаләтләрен
тапшыру турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Балалар һәм яшьләр эшләре идарәсенә (алга таба - Идарә) ведомство буйсынуындагы муниципаль учреждениеләргә карата функция һәм гамәлгә куючының вәкаләтләрен түбәндәге өлештә бирергә:

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы һәм гамәлгә куючы белән килештереп, барлык дәрәҗәдәге бюджетлар исәбеннән җирле бюджеттан субсидияләр рәвешендә кергән устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга акчалар белән эш итү;

муниципаль биремне төзү һәм раслау, аны финанс белән тәэмин итү, муниципаль биремнең үтәлешен тикшереп тору, муниципаль мөлкәткә ия булуның, аннан файдалануның һәм аның белән эш итүнең билгеләнгән тәртибен үтәү, шул исәптән билгеләнгән тәртиптә мөлкәтнең билгеләнешен һәм сакланышын тикшереп торуны гамәлгә ашырырга, оператив идарә итү хокукында муниципаль учреждениеләргә беркетелгән мөлкәтне билгеләү буенча булмаган артык мөлкәтне тартып алу буенча тәкъдимнәр бирергә;

ведомство буйсынуындагы учреждениеләр җитәкчеләрен кабул итү һәм эштән азат итү, аларга дисциплинар җәза бирү һәм кызыксындыру чаралары бирү, шул исәптән барлык төрдәге отпускларны бирү, хезмәт шартнамәләре (контрактлары) төзү;

ведомство буйсынуындагы учреждениеләргә беркетелгән муниципаль күчемле мөлкәтне (транспорт чараларыннан тыш) яңадан бүлү, баланс бәясе 100 000 сумга кадәр (мең сум) һәм күчемле мөлкәтне кабул итү-тапшыру актларын раслау буенча карарлар кабул итү.

2. Идарәгә буйсынучы учреждениеләрнең исемлеген расларга (1нче кушымта).

Зак. № 305-2000

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында PRAVO.TATARSTAN.RU урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Лаптевага йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе — А.М. Каюмов

Әлмәт муниципаль районы
Башкарма комитетының
«18» июль 2022 ел №1492
карары белән расланган
1 нче кушымта

Идарәгә буйсынучы учреждениеләрнең исемлеге

Табл. №1

| № № п/п | Учреждение исеме |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 1 | «Яшьләргә ярдәм итү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе |
| 2 | «Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (студентлар) формированиеләре үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе |
| 3 | «Әлмәт муниципаль районының «Каенкай» ял-сәламәтләндерү лагере» муниципаль бюджет учреждениесе |

Район Башкарма комитеты җитәкчесенең
икътисад буенча урынбасары
вазыйфаларын башкаручы Д.В. Косарев